КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 9 октябрь г.Казань № 815

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Һәлакәттән коткару хезмәтләрен, һәлакәттән коткару формированиеләрен, коткаручыларны һәм Татарстан Республикасы коткаручысы статусын алучы гражданнарны аттестацияләү буенча комиссия төзү турында» 2014 ел, 26 апрель, 274 нче карары белән расланган Һәлакәттән коткару хезмәтләрен, һәлакәттән коткару формированиеләрен, коткаручыларны һәм Татарстан Республикасы коткаручысы статусын ала торган гражданнарны аттестацияләү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Һәлакәттән коткару хезмәтләрен, һәлакәттән коткару формированиеләрен, коткаручыларны һәм Татарстан Республикасы коткаручысы статусын алучы гражданнарны аттестацияләү буенча комиссия төзү турында» 2014 ел, 26 апрель, 274 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 11 июнь, 462 нче; 2020 ел, 14 август, 686 нчы; 2021 ел, 30 декабрь, 1361 нче; 2023 ел, 8 декабь, 1586 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Һәлакәттән коткару хезмәтләрен, һәлакәттән коткару формированиеләрен, коткаручыларны һәм Татарстан Республикасы коткаручысы статусын ала торган гражданнарны аттестацияләү комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан А.С.Старковны, Н.Н.Хәбиповны, К.М.Чанышевны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Орлов Андрей Николаевичны | Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны, комиссия рәисен |
| Фәхриев Тимур Ревовичны | «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының Эзләү-коткару хезмәте» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе башлыгын |
| Яковлев Игорь Андреевичны | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенең янгын сүндерүне оештыру һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкару идарәсенә караган һәлакәттән коткару формированиеләре эшчәнлеген координацияләү бүлеге башлыгын (килешү буенча); |

Таһир Вәгыйзь улы Кәримуллинның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Янгыннан саклаучылар хезмәте» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе директоры»

Никита Андреевич Князьковның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсенә караган Магистраль торбаүткәргеч транспорты объектларына күзәтчелек итү буенча төбәкара бүлек башлыгы (килешү буенча)»;

Игорь Иванович Кацюрубаның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян бирергә:

«Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Казан эзләү-коткару отряды башлыгы («Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Идел буе төбәк эзләү-коткару отряды» федераль дәүләт казна учреждениесе филиалы) (килешү буенча)»;

Рөстәм Рабхат улы Хөсәеновның фамилиясен, исемен, атасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хөсәенов Рөстәм Рабхат улы».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин